**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**31 гыйнвар, 2022 ел** **№ 145**

**Биектау муниципаль районы Советының «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм оешмаларга биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган Биектау муниципаль районы милкендәге Муниципаль мөлкәт исемлеген (җир кишәрлекләреннән тыш) формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2016 елның 28 сентябрендәге 87 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм максатларында, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм оешмаларга биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган Биектау муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәт исемлеген (җир кишәрлекләреннән тыш) формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2016 елның 28 сентябрендәге 87 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә һәм 1.1 пунктында «кече һәм урта эшкуарлык субъектлары» сүзләреннән соң «индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә;

2.2 пунктта «кече һәм урта эшкуарлык субъектлары» сүзләреннән соң «индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә;

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Совет рәисенең урынбасары,
муниципаль район Башлыгы урынбасары Ә.Ш. Шакиров